КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1066

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 589 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.7, 2.9 – 2.12, 2.14 нче пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2.16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16. Каты коммуналь калдыкларны аерым җыюның дуаль схемасын файдаланганда органик калдыклардан һәм тормыш эшчәнлеге калдыкларыннан тормаган калдыклар рециклингның халыкара тамгасы – «ябык цикл» символы булган яшел төстәге «Мебиус элмәге» төшерелгән сары төсле индикацияле контейнерда урнаштырыла.

Органик калдыклардан һәм тормыш эшчәнлеге калдыкларыннан торган каты коммуналь калдыклар соры төсле индикацияле контейнерда саклана.»;

2.18 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Соры төсле индикацияле контейнерларда органик калдыклардан һәм тормыш эшчәнлеге калдыкларыннан торган каты коммуналь калдыклар урнаштырыла.»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Икенчел матди ресурслар сыйфатында файдаланырга тиешле каты коммуналь калдыкларны туплау утиль кабул итү пунктларында морфологик компонентлар: кәгазь һәм (яки) картон, пластмассалар, пыяла, алюминий банкалар, тукыма әйберләре һ.б. буенча аерым-аерым гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

3.2, 8.1, 8.3, 8.4, 8.9, 8.10 нчы һәм 9.3 нче пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин